АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2019 № 1908

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 1101 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы финанс Министрлыгының 2019 елның 12 августындагы 03-16/6427 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 1101 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенә (алга таба - Тәртип) үзгәрешләр кертеп, яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.В. Калашниковага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Нуриев

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 1908 ” 28.12.20 ел
карарына кушымта

# Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип мәктәпкәчә белем бирә торган белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен билгеләү һәм түләү механизмын (алга таба - компенсация) билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 карары белән расланган Тәртиптә, компенсация ата-анага (законлы вәкилгә) баласы булган һәм гаиләдә кеше башына уртача айлык керем 20 мең сумнан артмаган очракта, өстәмә компенсация билгеләнә (алга таба-мөрәҗәгать итүче).

1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 карары белән билгеләнә.

1.4. Компенсация күләме формула буенча исәпләнә:
ДК= Ф х (100-МДД) - К , монда:
ДК - компенсация күләме;
Ф - мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм карап-тәрбияләп торган ата-ана түләвенең күләме;
МДД - мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм карап-тәрбияләп торган өчен таблицага туры китереп билгеләнгән ата-ана түләвенә

гражданнарның мөмкин булган чыгымнары;
К - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 карары белән расланган Тәртиптә исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм карап-тәрбияләп торган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме.

*Таблица*

**Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм карап-тәрбияләп торган өчен гражданнарның ата-ана түләвен түләү чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше**

| Бер гаилә әгъзасына табыш күләме | Ата-ана түләвен түләүгә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше (%) | | |
|---|---|---|---|
| | 1 балага | 2 балага | 3 балага һәм аннан соңгы балаларга |
| мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән бер кешегә яшәү минимумы күләменә кадәр (18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләр өчен) | 0 | 0 | 0 |
| 10000 сумга кадәр рублей | 60 | 38 | 23 |
| 10 001 сумнан башлап 15 000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15 001 сумнан башлап 20 000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |
| 20 000 сумнан артык | 100 | 100 | 100 |

1.5. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм карап-тәрбияләп торган өчен гражданнарның ата-ана түләвен түләү чыгымнарының максималь мөмкин булган өлешен билгеләгәндә гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алына:

18 яшькә җитмәгән һәм иждевениедә торган балалары, шул исәптән

хастаханәләрдә, балалар шифаханәләрендә дәваланучы балалары, шулай ук интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнгән өчен ата-аналары алар өчен өлешчә акча керткән балалар;

18-23 яшьлек балалар (никахта тормаучы), көндезге форма буенча укучы, шул исәптән дәүләтнеке булмаган уку учреждениеләрендә белем алучы балалар, ата-аналары белән бергә яшәү-яшәмәү фактына карамастан;

гаиләдә яшәүче үги малайлар һәм үги кызлар, әгәр алар башка әтиәнинең гаиләсендә исәпкә алынмаган булса;

гражданнар гаиләләрендә опекага алынган балалар;

тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар.

1.6. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен гражданнарның ата-ана түләвен түләү чыгымнарының максималь мөмкин булган өлешен билгеләгәндә гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алымый:

аларга карата атасы да, анасы да (тулы булмаган гаиләдә – атасы яки анасы) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән;

тулы дәүләт тәэминатында торучылар.

## II. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча (тору урыны буенча гариза бирүченең теркәлүе булмаган очракта) Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә, ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар - тиешле белем бирү оешмасын теркәү урыны буенча түбәндәге документларны тапшыра (алга таба - Үзәк бүлеге):

банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп (банк яисә башка кредит оешмасы аша компенсация алганда), әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча компенсация билгеләү турында гариза (алга таба - гариза);

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәрен раслый торган документлар, компенсация бирү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы алты календарь ай эчендә (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турындагы белешмәләрдән тыш);

бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсен - Татарстан Республикасыннан читтә бала (балалар) туу акты дәүләт теркәвенә алынган очракта;

Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан

гомуми белем бирү оешмасыннан, һөнәри белем бирү оешмасыннан һәм югары белем бирүче мәгариф оешмасыннан уналты яшьтән унсигез яшькә кадәрге баланы (балаларны) укытуны раслый торган белешмә;

никахлашуны Татарстан Республикасыннан читтә дәүләт теркәвенә алган очракта - никах турындагы таныклыкның күчермәсен;

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычлы затлар өчен ышанычнамә;

гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән, раслаучы (раслый торган) документлар (ирекле рәвештә);

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булу;

гариза бирүченең шәхси мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда аларның исеменнән эш итәргә вәкаләтләре.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатьне таныклый торган документны күрсәтелә.

2.2. Үзәкнең бүлеге ведомствоара запрослар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, электрон рәвештә, компенсация билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләрне ала:

балаларның тууын дәүләт теркәве турында белешмәләр - Татарстан Республикасы территориясендә баланың (балаларның) туу акты теркәлгән очракта;

никахлашуны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр - Татарстан Республикасы территориясендә никахлашуны дәүләт теркәвенә алган очракта;

опека (попечительлек) билгеләү турында, баланы тәрбиягә бала алучы гаиләгә тапшыру турында, баланы матди карап торуга опекун (попечитель) тарафыннан алына торган акчаларның күләме һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүнең суммалары турында белешмәләр;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яисә ата-ана хокукларыннан чикләү турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан эш бирүче (иминләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка түләүләр суммасы турында белешмәләр;

эшсез гражданнарга эшсезлек буенча пособие күләме, матди ярдәм һәм башка түләүләр, шулай ук һөнәри белем бирү чорында гражданнарга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм турында һәм мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы белән өстәмә һөнәри белем алу, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга түләүләр, һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашу чорында, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга түләүләр турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан башкарыла торган пенсионерларның пенсияләре күләме, компенсация түләүләре һәм өстәмә айлык матди тәэминаты турында белешмәләр;

Россия эчке эшләр Министрлыгы һәм Россия оборона Министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала табу буенча пособие күләме турында белешмәләр;

вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособие күләме турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары яисә социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган йөклелекнең иртә срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер мәртәбә бирелә торган пособие күләме турында белешмәләр

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган баланы карау буенча айлык пособие күләме турында белешмәләр;

социаль яклау органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль түләүләр күләмнәре турында белешмәләр;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында белешмәләр, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса түләүл күләмнәре турында белешмәләр;

даими яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында уналты яшьтән унсигез яшькә кадәрге баланы (балаларны) укытуны узу турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең паспортының дөреслеген раслау турында белешмәләр;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткәндә.

Мөрәҗәгать итүчеләр үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырырга хокуклы.

2.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның ризалыгы булганда, компенсацияне билгеләү Россия Федерациясе Пенсия фондында компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алып 12 айга кадәр булган соңгы алты ай эчендә булган гаилә әгъзаларының керемнәре турында белешмәләр нигезендә башкарыла.

2.4. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнгә гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларын алучы булса, мөрәҗәгать итүче керемнәр турында белешмәләр тапшыру бурычыннан азат ителә.

2.5. Әгәр мөрәҗәгать итүче торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия алучы гаиләсенә, я балага айлык пособие алучы гаилә составына керсә, аның гаризасы буенча билгеләнгән компенсация, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларны, яисә балага айлык пособиене исәпкә алып, күрсәтелгән түләүләрне алу чорына яңадан билгеләнергә мөмкин.

2.6. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктының сигезенче абзацында күрсәтелгән белешмәләр үзәге бүлекчәсендә булган очракта, шулай ук әлеге Тәртипнең 2.2 пунктының алтынчы һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән белешмәләр, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү көненә кадәрге алты ай эчендә алынган булса, алар компенсация билгеләгәндә кулланыла.

2.7. Үзәк бүлеге гариза теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә барлык кирәкле документлар белән компенсация билгеләү турында я аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны мөрәҗәгать итүчегә (язмача рәвештә почта адресы буенча, электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша) күрсәтелгән ысул белән җиткерә.

2.8. Компенсация барлык кирәкле документлар белән гариза биргән айдан билгеләнә һәм 6 ай дәвамында түләнә.

2.9. Мөрәҗәгать итүченең компенсация алу хокукын раслаучы белешмәләр үзәге бүлекчәсе булганда, компенсация аңа, гражданның мөрәҗәгатеннән башка, яңа срокка автомат рәвештә билгеләнә.

2.10. Булган мәгълүматлар җыелмасы нигезендә ачыкланган һәм аны алуга хокукның булмавы компенсация билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Гариза бирүче бирелгән белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның чынлыгы өчен җаваплы.

3.2. Законда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның гаризалары һәм күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Компенсация алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә тапшырыла торган гаризалар һәм документлар (белешмәләр) электрон имза белән Россия Федерациясе законнары нигезендә имзалана һәм гомуми файдаланудагы электрон чыганаклардан һәм (яисә) мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, шул исәптән «Интернет»

челтәрен дә кертеп, тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эшләүче затлардан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрергә мөмкин;

туу турында таныклыклары Татарстан Республикасыннан читтә бирелгән балалары булган гариза бирүчеләрдән; мөрәҗәгать итүчеләрдән, әгәр барлык балаларының атасы (анасы) белән никахта тормаучы һәм ялгыз ана булмаса; Татарстан Республикасы территориясеннән читтә никахлашкан гариза бирүчеләрдән; мөрәҗәгать итүчеләрдән, әгәр аның һәм (яисә) гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе Пенсия фондында булмаган керемнәре булса (Россия Федерациясе социаль иминият Фондында яисә халыкны социаль яклау бүлегендә булган вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек буенча һәм ана булу белән бәйле түләүләрдән тыш; халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре аша алына торган пособиеләр; шәхси ярдәмче хуҗалык алып барудан керемнәр).

3.3. Үзәкнең бүлеге документларның дөреслегенә һәм тапшырылган белешмәләрнең дөреслегенә шик туган очракларда мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган белешмәләргә өстәмә тикшерү башкарырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең өстәмә тикшерүе уздырылган очракта, билгеләнү турында я компенсация билгеләүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән тикшерүне уздырганнан соң, әмма Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать иткән вакыттан 30 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

3.4. Компенсация суммасы мөрәҗәгать итүченең банк счетына күчерелә. Сәламәтлеге торышы буенча мөмкинлекләре булмаган мөрәҗәгать итүчегә, яше, җәяүле яисә транспортта банк счетын ачарга һәм алардан файдалана алмау аркасында, компенсация түләү (китерү) элемтә оешмасы аша яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән башка оешмалар акчалата түләүләрне китереп торучы башка оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

3.5. Гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән банк счетларына күчерү һәм почта элемтәсе белән тәэмин итүче яисә башка төр оешма тарафыннан акчалата түләүләр китерүне гамәлгә ашыручы компенсация исәпхисап ае дәвамында башкарыла.

3.6. Гражданнар компенсация түләүне туктату (мәгариф оешмасын алмаштыру, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, мөрәҗәгать итүченең үлеме) сәбәпле, мондый хәл килеп туган вакыттан бер айдан да соңга калмыйча, вәкаләтле органга хәбәр итәргә тиеш.

3.7. Түләүне туктатуга китерә торган шартлар килеп туганда, түләү тиешле шартлар туган айдан соң килүче айдан туктатыла.

3.8. Артык түләнгән компенсация суммалары, белә торып дөрес булмаган белешмәләре булган документлар тапшыру, өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү нәтиҗәсендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле органның казна счетына кертү юлы белән каплана, ә гариза бирүче кире кайтарудан баш тарткан очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри алына.

3.9. Вәкаләтле орган гаебе белән вакытында алынмаган компенсация узган вакыт эчендә срогы чикләнмичә түләнә.

3.10. Мөрәҗәгать итүче вафат булган очракта, аңа исән чакта түләнмәгән компенсация суммалары мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас итеп алына.

3.11. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

*Кушымта*

"Республика матди ярдәм үзәге" ГКУ
____бүлегенә___________
(компенсация түләүләр)
______________________________________
муниципаль районы (шәһәр округы)

ГАРИЗА № ____

_________ ________ 20__ ___ ел.

Мин,________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

| Шәхесне раслаучы документның исеме | Сериясе һәм (яки) номер | Кем тарафыннан бирелгән | Бирү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яшәүченең адрес буенча:
______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индекс, телефон, электрон почта адресы күрсәтелгән)
нигезендә гамәлдәге:
______________________________________________________________________,
(ышанычлы зат яки законлы вәкил мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслаучы документ реквизитлары)
Снилс (алучы) ________________________________, билгеләвегезне сорыйм
(дәүләт хезмәтләрен алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
яшәүченең адресы буенча:
______________________________________________________________________
(почта индексы, дәүләт хезмәтләрен алучының яшәү урыны буенча теркәү адресы)
______________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучының шәхесен раслаучы документ реквизитлары)
______________________________________________________________________

мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсацион түләү

Түбәндәге документларны тәкъдим итәм (белешмәләр):

| номерлы | Документлар исеме | Экземплярлар саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | | |

Түләү алучының гаилә хәле (составы)

| номерлы | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне) | Кардәшлек | Паспорт реквизитлары (бала туу турында таныклык) |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |

Гаризада күрсәтелгән балалар (бала) тулы дәүләт тәэминатында, шулай ук аларга карата (аның) булмавын раслыйм)

___________________________________________

(дәүләт хезмәтен алучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукларында чикләнмәгән

__________ ______________________

(имза, расшифровка имза гариза бирүченең)

___________________________________________

(баланы опекага алган органның исемен һәм урынын күрсәтергә)

Уналты яшьтән өлкәнрәк бала (балалар) укый:

______________________ ______________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасы исеме)

______________________ ______________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасы исеме)

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:

счет реквизитлары

___________________________________________

(банкта яки башка кредит учреждениесендә законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәтен алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан ачылган шәхси счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге реквизитлары ______________________

(почта бүлеге реквизитлары күрсәтелә дәүләт хезмәтен алучыга яисә аның законлы вәкиленә)

Бирелгән мәгълүматларның дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның чынлыгы өчен җавап тотам ______________________

(гариза бирүченең имзасы)

Мәгълүмат алуга (мауга), шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да килешәм:

почта адресы буенча язма формада

телефонга смс-хәбәр ______________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

электрон почта адресы буенча ______________

(электрон почта адресы)

дәүләт бүлмәсенә шәхси кабинет аша
республиканың мәгълүмат системасы
Татарстан «Дәүләт порталы
һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү» ____________

(гариза бирүченең имзасы)

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга, шул исәптән, яңа срокка автоматик билгеләнүгә, соңгы 6 айда Россия Федерациясе Пенсия фондында булган эш бирүче (иминләштерүче) тарафыннан минем файдага күчерелгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турындагы белешмәләр нигезендә, социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 12 айдагы соңгы 6 ай эчендә компенсацион түләү билгеләү белән килешәм.
________________________________

(гариза бирүченен имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде _________ _________ ____________

(белгечкә имза кую датасы, имзасын расшифровка)

---

Аеру линиясе

Раслама-хәбәрнамә

Гариза бирүченең теркәлү номеры ______________
Документлар саны ____________ бер. битләрдә
Документлар кабул ителде __________ _________ ___________________ ____

(вазыйфасы) (имза) (имза расшифровка) (дата)